РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Козяково-Челнинского
сельского поселения
Рыбно Слободского
муниципального района

Иванова ул., дом 26,
с.Козяково-Челны, 422668

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Балык Бистәсе
муниципаль районы
Казаклар Чаллысы
авыл җирлеге
башкарма комитеты

Иванов урамы, 26 нче йорт,
Казаклар Чаллысы авылы, 422668

Тел.: (84361) 32310 факс: (84361)32310, эл.адрес: Kcn.Rs@tatar.ru

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.01.2024 Казаклар Чаллысы авылы № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегендә җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм "Җирләү һәм мәет кую эше турында" 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законына, «2023 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 30 гыйнварындагы 119 номерлы карарына, "Татарстан Республикасында җирләү һәм мәет кую эше турында" Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарына тәңгәлләштереп, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 һәм 2 кушымтада күрсәтелгәнчә 8370,20 сум күләмендә билгеләргә һәм 2024 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 31 гыйнварында кабул ителгән "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегендә җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында"гы 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Казаклар Чаллысы авылы, Яңа урамы адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Казаклар Чаллысы авылы, Иванов урамы, 26 нчы йорт; Иванаево авылы, Калинин урамы,18 йорт; Бирдебәк авылы, Мәктәп урамы, 5 йорт;Үри Чаллысы авылы, Гаврилов урамы, 24 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Казаклар Чаллысы авыл җирлеге башлыгы
вазифасын башкаручы Ф.Х.Хасаншин

Татарстан Республикасы Балык
Бистәсе муниципаль районы
Казаклар Чаллысы авыл җирлеге
Башкарма комитетының
22.01.2024 елның 1 номерлы
карарына кушымта 1

**2024 елның 1 февраленнән җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 5929,40 |
| 3. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка (крематорийга) күчерү (алып бару) | 841,20 |
| 4. Җирләү (мәетне яндыру, соңыннан көле салынган урнаны бирү белән) | 1599,60 |
| Җәмгысе: | **8370,20** |

Татарстан Республикасы Балык
Бистәсе муниципаль районы
Казаклар Чаллысы авыл җирлеге
Башкарма комитетының
22.01.2024 елның 1 номерлы
карарына кушымта 2

**2023 елның 1 февраленнән җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 2964,70 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2964,70 |
| 4. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка күчерү (алып бару) | 841,2 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1599,60 |
| Җәмгысе: | **8370,20** |